**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Мамыш торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын карары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Мамыш торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Мамыш торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Мамыш авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Мамыш авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу)»

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Мамыш авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.